# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Камышлы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

14 ноябрь 2025 ел №1

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2025 елның 14 ноябредә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез 2026 елда Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,

- 1 төркем инвалидларыннан,
- көндезге уку формасында укучы студентлардан,
- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан,
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы

гражданнардан тыш 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамына вак таш сатып алу, ташу, салу);
- урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, авыл урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү );
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу хезмәтләре, юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту)

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 53 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны – 27 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 27 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; җыенда катнашучы 0 кеше «Каршы» позициясе өчен тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге составына керүче Камышлы авылыдна узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. «Сез 2026 елда Чалпы авыл җирлеге Камышлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган,

- 1 төркем инвалидларыннан,

- көндезге уку формасында укучы студентлардан,
- махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан,
- Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы

гражданнардан тыш 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамы урамына вак таш сатып алу, ташу, салу);
- урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, авыл урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү );
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу хезмәтләре, юлларын һәм территорияләрен кардан чистарту) кабул ителгән.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: ТР, Азнакай муниципаль районы, Чалпы авылы, Үзәк урам, 39 йорт, Камышлы авылы, Яшьләр урамы урамы, 35 йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы _________ А.М.Мөхәмәтшин